РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул.Ленина, д.60,
с. Старый Мензелябаш, 423354
Телефон: (85559) 4-53-46
E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 60 йорт,
Иске Минзәләбаш авылы, 423354
Телефон: (85559) 4-53-46
E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru

ОКПО 04311866, ОГРН 1021601312237, ИНН/ КПП 1636001393/ 163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2015 г. № 13

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләгән затка пенсиягә чыкканга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бирү тәртибен расларга 1 нче кушымта нигезендә.
2. Әлеге карарны Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе,
Иске Минзәләбаш авылы башлыгы А. Р. Мияссәрова

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының
15.06.2015 ел, № 13 карарына
1нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮЧЕ ЗАТКА ПЕНСИЯГӘ ЧЫГУ СӘБӘПЛЕ БЕР ТАПКЫР БИРЕЛӘ ТОРГАН АКЧАЛАТА БҮЛӘК БИРҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү (алга таба - бер тапкыр бүләкләү) түләү тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле сайланулы орган әгъзасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»2009 елның 12 декабрендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде .

2. Пенсиягә чыкканда муниципаль вазыйфаны биләүче затка, муниципаль хезмәт стажы 5 ел булганда хезмәткә акчалата түләүнең бишләтә күләмдә һәм муниципаль хезмәтнең алдагы һәр тулы елы өчен – өстәмә рәвештә хезмәткә акчалата түләүнең 0.5 күләмендә , әмма затның хезмәткә акчалата түләүнең уннан артык булмаган күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәттән муниципаль вазыйфа биләүче зат эштән киткән көнгә билгеләнә.

3. Бер тапкыр бүләкләү түләү турындагы карар җирле үзидарәнең вәкиллекле органы (муниципаль вазыйфаны биләүче зат) тарафыннан кабул ителә, пенсиягә чыккач муниципаль вазыйфа биләүче затны эштән азат итү турында җирле үзидарә органы (алга таба – Муниципаль орган) карары кабул ителгәндә бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Муниципаль орган тарафыннан бер тапкыр акчалата бүләкләү муниципаль вазыйфаны биләүче зат эштән азат ителгәнче үк яки муниципаль вазыйфаны биләүче зат эштән азат ителгәч бер айдан да соңга калмыйча башкарыла.

5. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә хезмәткә айлык акчалата түләү составына түбәндәгеләр кертелә:
айлык акчалата стимул;
хезмәт хакы;
тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә.

6. Бер тапкыр бүләкләү хезмәт кенәгәсендәге билге белән бер тапкыр түләнә. Пенсиягә чыкканнан соң һәм муниципаль хезмәтне туктаткач, граждан муниципаль хезмәткә кергәндә бер тапкыр бирелә торган бүләк кабат түләнми.